Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге Советының утыз дүртенче утырышы

Шәле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

29 май, 2024 ел № 96

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башлыгы, Шәле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында» 2021 елның 9 апрелендәге 18 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Советы карарына (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2022 елның 29 декабрендәге 59 номерлы Шәле авыл җирлеге Советы карары белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.1 пунктчасында «19 039» санын «19 991» саннарына алмаштырырга;

1.2. 1 пунктның 1.2 пунктчасында «12688» санын «13323» саннарына алмаштырырга;

1.3. 1 пунктның 1.3 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 1 кушымтаның икенче абзацында «10,36» санын «14,12» саннарына алмаштырырга;

1.5. 8 кушымтаның 6 пунктында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә

Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов